**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 114** **28.12.2018**

**2018-2027 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 26, 57.1 статьялары, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 29 декабрендәге 456-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге транспорт инфраструктурасының тотрыклы һәм нәтиҗәле үсешен тәэмин итү максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018-2027 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын (алга таба – пргограмма) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуын имза салынганнан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Н.Ә. Гатина**